# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

26 ноябрь 2025 ел № 1

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 26 ноябрьдә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде «2026 елда балигъ булган һәр кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә үзара салымны кертүгә ризамы Сез? " дигән сорау буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлегенең Ташсу авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару буенча:

а) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

б) урам яктырту җайланмасы;

в) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

г) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

д) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 78 (җитмеш сигез) катнашучы кертелгән, 42 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 54% тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә билгеләнде:
халык җыенында 42 (кырык ике) катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу авылында халык җыены булып узды, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2026 елда үзара салым акчасын Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Ташсу авылы территориясендә яшәү

урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2000 (ике мең) сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

б) урам яктырту җайланмасы;

в) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

г) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

д) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче,
Суыксу авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев